КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 24 декабрь г.Казань № 1131

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 7 август, 674 нче; 2013 ел, 14 февраль, 103 нче; 2013 ел, 30 ноябрь, 936 нчы; 2014 ел, 9 июль, 479 нчы; 2016 ел, 27 сентябрь, 686 нчы; 2017 ел, 1 ноябрь, 830 нчы; 2017 ел, 12 декабрь, 976 нчы; 2019 ел, 23 июль, 618 нче; 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче; 2021 ел, 27 март, 177 нче; 2023 ел, 17 август, 983 нче; 2023 ел, 29 декабрь, 1752 нче; 2024 ел, 31 июль, 608 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат үзәге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «а» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы;»;

15 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Локоло» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын булдыру турында» 2022 ел, 4 август, 758 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 14 август, 975 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын булдыру турында»;

1 пунктта «Локоло» сүзен «ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Система Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карары нигезендә Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә физик һәм юридик затлар белән хезмәттәшлек барышында кулланыла торган, Россия Федерациясе Торак кодексының $44^1$ статьясындагы 2 пункты, $47^1$ статьясы нигезендә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышын читтән торып тавыш бирү рәвешендә үткәрү өчен, «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законның 17 һәм $17^1$ статьялары нигезендә коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышын читтән торып һәм турыдан-туры катнашып-читтән торып тавыш бирү рәвешендә үткәрү өчен һәм күпфатирлы йортлар, бакча һәм яшелчә җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле идарә итү, шул исәптән кирәкле мәгълүмат алмашу өчен цифрлы инструмент булдыру максатларында физик һәм юридик затлар, идарәче оешмалар, коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре, республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеге процессларын автоматлаштыру өчен билгеләнгән сервистан гыйбарәт Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы булып тора дип билгеләргә.»;

3 пунктта «Локоло» сүзен «ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләре идарәләренә, торак яки торак-төзелеш кооперативларына, башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына, коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләренә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына күчемсез мөлкәт милекчеләренең гомуми җыелышын читтән торып яки турыдан-туры катнашып-читтән торып тавыш бирү формасында электрон рәвештә үткәргәндә Системаны куллануны һәм Нигезләмәгә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$. Идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләре идарәләренә, торак яки торак-төзелеш кооперативларына, башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына Россия Федерациясе Торак кодексының 45 статьясындагы 6 өлеше нигезендә күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре тавышлары кворумы җыелганда күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышын үткәрү турында күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре мөрәҗәгатьләрен

үз вакытында карап тикшерү максаты белән Системада исәпкә алу язмасын һәм Системадагы шәхси кабинетка керү мөмкинлеген булдыруны тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган «Локоло» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәдә:

исемендә «Локоло» сүзен «ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 пунктта «Локоло» сүзен «ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктның беренче абзацында «Локоло» сүзен «ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. «ТР дәүләт хезмәтләре платформасы 2.0» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Система) – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 28 октябрь, 864 нче карары нигезендә Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә физик һәм юридик затлар белән хезмәттәшлек итү системасы.

Система күпфатирлы йортлар, бакча һәм яшелчә җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле идарә итү, шул исәптән кирәкле мәгълүмат алмашу өчен цифрлы инструмент булдыру максатларында күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышын читтән торып тавыш бирү формасында үткәрү, коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәтләре әгъзаларының гомуми җыелышын читтән торып һәм турыдан-туры катнашып-читтән торып тавыш бирү формасында үткәрү процессларын тәэмин итү, физик һәм юридик затлар, идарәче оешмалар, коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре, республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеге процессларын автоматлаштыру өчен билгеләнгән «Локоло» сервисын (алга таба – Сервис) һәм башка берләштерелгән мәгълүмат системаларын һәм сервисларны үз эченә ала.»;

1.3 пунктның өченче абзацында «Татарстан Республикасының республика башкарма хакимият органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«күпфатирлы йортлар, бакча һәм яшелчә җир кишәрлекләре белән нәтиҗәле идарә итү, шул исәптән кирәкле мәгълүмат алмашу өчен цифрлы инструмент булдыру максатларында физик һәм юридик затлар, идарәче оешмалар, коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары хезмәттәшлеге процессларын автоматлаштыру;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр, шулай ук башка хезмәтләр күрсәтү өчен рәсми сораулар җибәрү мөмкинлеге бирү;

төрле мәгълүмат системаларын үзара интеграцияләүне тәэмин итү хисабына ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлеген, мәгълүматтан файдалануны оештыру;

күпфатирлы йортлар һәм коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре эшчәнлеге белән идарә итү сыйфатын яхшырту.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Система түбәндәге функцияләрне башкара:

дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт һәм башка хезмәтләр күрсәтү турында рәсми сорау, шулай ук дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар бирү;

электрон рәвештә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр һәм башка хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеге;

электрон рәвештә дәүләт хезмәтләреннән һәм муниципаль хезмәтләрдән файдалану өчен мөрәҗәгать итү барышында физик затларга мәгълүмати ярдәм күрсәтеп тору;

Идентификация һәм аутентификация бердәм системасыннан файдаланып, физик яки юридик затларны яисә аларның вәкаләтле вәкилләрен идентификацияләү һәм аутентификацияләү;

Системадан файдаланучылар өчен профильләр булдыру.

Сервис түбәндәге функцияләрне башкара:

күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышын читтән торып тавыш бирү рәвешендә үткәрү;

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законның 17 һәм $17^1$ статьялары шартларын үтәп, коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышын читтән торып һәм турыдан-туры катнашып- читтән торып тавыш бирү рәвешендә үткәрү;

күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышын үткәрү турында күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре мөрәҗәгатьләрен формалаштыру һәм аларны идарәче оешмаларга, торак милекчеләре ширкәтләре идарәләренә, торак яки торак-төзелеш кооперативларына, башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына җибәрү;

идарәче оешмалар, торак милекчеләре ширкәтләре идарәләре, торак яки торак-төзелеш кооперативлары, башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары тарафыннан күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышын үткәрү турында күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү;

күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышын үткәрү турында хәбәрләрне, күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышында кабул ителгән карарларны, тавыш бирү йомгакларын, күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми җыелышындагы көн тәртибе мәсьәләләре буенча күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләренең гомуми

җыелышлары беркетмәләрен, тавыш бирүгә чыгарылган мәсьәләләр буенча күпфатирлы йорттагы бүлмәләр милекчеләре карарларын урнаштыру;

коммерциягә карамаган бакчачылык яки яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышын үткәрү турында хәбәрләрне, гомуми җыелышта кабул ителгән карарларны, тавыш бирү йомгакларын, гомуми җыелышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча беркетмәләрне урнаштыру, цифрлы архив алып бару, мәгълүмати постлар, сораштырулар һәм белдерүләр урнаштыру;

коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәте һәм коммерциягә карамаган яшелчәчелек ширкәте әгъзаларының гомуми җыелышында тавыш бирүдә катнашучыларның шәхесен электрон яки башка техник чараларны кулланып тикшерү; әлеге тикшерү ширкәт әгъзалары реестрында белешмә бирелгән һәм ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышында үзенең катнашуы турында әлеге реестрда күрсәтелгән электрон почта адресыннан һәм (яки) телефон номерыннан хәбәр җибәреп теләк белдергән затның тавыш бирүдә катнашу фактын раслаудан гыйбарәт;

идарәче оешмалар, күпфатирлы йортлар, коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек ширкәтләре турында җыелма мәгълүматларны һәм санлы күрсәткечләрне үз эченә алган статистика формалаштыру;

физик һәм юридик затлардан алынган мәгълүмати постлар, белдерүләр һәм хәбәрләр бастырып чыгару;

физик һәм юридик затлар өчен идарәче оешмалардан алынган мәгълүмати постлар, сораштырулар, белдерүләр һәм хәбәрләр бастырып чыгару;

физик һәм юридик затларның чат режимында төркемле һәм индивидуаль онлайн-коммуникацияләрен булдыру;

физик һәм юридик затларның идарәче оешмалар белән чат режимында онлайн-коммуникацияләрен гамәлгә ашыру.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Система түбәндәге функциональ модульләрдән тора:

«Локоло» модульләр/сервислар/ярдәмче системалар җыелмасы;

«ТР дәүләт хезмәтләре» модульләр/сервислар/ ярдәмче системалар җыелмасы;

«Хезмәтләр операторының шәхси кабинеты» ярдәмче системасы;

«Муниципаль район вәкиленең шәхси кабинеты» ярдәмче системасы;

«Баш» модуле;

«ИАБС цифрлы профиле аша авторизация» модуле;

«Шәхси профиль» модуле;

Системаның промо-сайты.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин